РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«28» декабрь 2022г. г. Альметьевск №186

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2018 елның 11 маендагы 233 номерлы «Әлмәт муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләре, җирле үзидарәнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы сайланулы вазыйфаи затларының, контроль-хисап палатасы рәисе, рәис урынбасары, аудиторларның хезмәте ечен түләү тәртибе һәм шартлары турында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең тикшерү - хисап органнары рәисләренең, рәис урынбасарларының, аудиторларының, муниципаль хезмәткәрләрнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының хезмәт ечен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү хакында «2022 елның 17 сентябрендәге 1015 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә», Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы тәкъдимнәре белән

Әлмәт муниципаль районы Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2018 елның 11 маендагы 233 номерлы ««Әлмәт муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләре, җирле үзидарәнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы сайланулы вазыйфаи затларының, контроль-хисап палатасы рәисе, рәис урынбасары, аудиторларның хезмәте өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында»гы карарына (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2019 елның 30 сентябрендәге 323 номерлы, 2020 елның 30 октябрендәге 8 номерлы, 2021 елның 15 ноябрендәге 89 номерлы, 2021 елның 16 декабрендәге 103 номерлы, 2022 елның 20 апрелендәге 136 номерлы, 2022 елның 5 октябрендәге 166 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр исәпкә алып), түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. Әлмәт муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләрен, җирле үзидарәнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы сайланулы вазыйфаи затларына, Контроль-хисап палатасы рәисенә, рәис урынбасарына, аудиторына хезмәт ечен түләү тәртибе һәм шартларында:

1.1.1 бүлектә:

а) 3 пунктның беренче абзацында «2,37» санын «2,28» санына алмаштырырга;

б) 4 пунктның беренче абзацында «1,07» санын «0,81» санына алмаштырырга;

в) 5 пунктның беренче абзацында «1,07» санын «1,31» санына алмаштырырга;

г) 6 пунктның беренче абзацында «0,84» санын «1,05» саннарына алмаштырырга;

д) 6.1 пунктының беренче абзацында «0,65» санын «0,84» санына алмаштырырга;

1.1.2 нче бүлектә:

а) 8 пунктның 4 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) түләү тәртибе муниципаль орган бурычларын һәм функцияләрен үтәүне, вазыйфаи инструкцияне үтәүне тәэмин итүне исәпкә алып, яллаучы (эш бирүче) вәкиле тарафыннан билгеләнә торган аеруча мөһим һәм катлаулы биремнәрне үтәгән өчен, шул исәптән хезмәт өчен түләүнең билгеләнгән фонды чикләрендә вазыйфаи окладның бер проценты күләмендә аеруча меһим һәм катлаулы биремнәрне үтәгән өчен айлык премия;»;

б) 8 пунктның 5 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5) вазыйфаи окладның 18 процентыннан артмаган күләмдә ай саен акчалата бүләкләү, моңа муниципаль хезмәткәрнең җирле үзидарә органнары структурасы стандартларын муниципаль хезмәт вазыйфасына кертү белән бәйле рәвештә җирле үзидарә органнары структурасын үзгәртеп корганда билгеләнү очрагы керми, ул элек биләгән вазыйфа буенча акчалата бүләкләү күләмен исәпләгәндә, муниципаль хезмәткәрнең акчалата күләмен элек биләгән вазыйфасы буенча акчалата түләү күләменә җиткерүне тәэмин итүне исәпкә алып башкарыла;»;

1.2. карарга 1 нче кушымтадагы таблицаны яңа редакциядә бәян итәргә:

«Әлмәт муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең
вазыйфаи окладлары күләмнәре

(сумнарда)

| «Вазыйфаның исеме | Вазыйфаи оклад |
|---|---|
| Башкарма комитет җитәкчесе | 38 064 |
| Башкарма комитет җитәкчесенең беренче урынбасары | 35 146 |
| Район Советы аппараты җитәкчесе | 35 146 |
| Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары | 34 512 |
| Җирле үзидарәнең башка органы җитәкчесе | 34 385 |
| Башкарма комитетның аппарат (эшләр идарәчесе) җитәкчесе | 31 974 |
| Башка җирле үзидарә органы җитәкчесе урынбасары | 31 213 |
| Идарә җитәкчесе , мөстәкыйль бүлек җитәкчесе (медире), башкарма комитетның башка структур бүлекчәсе җитәкчесе | 26 138 |

| | |
|---|---|
| Идарә җитәкчесе урынбасары, мөстәкыйль бүлек җитәкчесе урынбасары (медире), башкарма комитетының башка структур бүлекчәсе җитәкчесе урынбасары | 21 570 |
| Район башлыгы ярдәмчесе, Башкарма комитет җитәкчесе ярдәмчесе, район башлыгы киңәшчесе, Башкарма комитет җитәкчесе киңәшчесе | 21 570 |
| Башкарма комитетның идарә составындагы бүлек җитәкчесе | 21 570 |
| Сектор медире | 20 048 |
| Баш белгеч | 19 286 |
| Әйдәүче белгеч | 18 144 |
| 1 категорияле белгеч, 2 категорияле белгеч, белгеч | 16 241» |

1.3. карарның 3 нче кушымтасындагы таблицаны яңа редакциядә бәян итәргә:

«Әлмәт муниципаль районының үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затлары, тикшерү-хисап палатасы рәисе, рәис урынбасары, аудиторларының айлык акчалата бүләкләү күләме

(сумнарда)

| Вазыйфаның исеме | Айлык акчалата бүләкләү күләме |
|---|---|
| Башлык | 38 585 |
| Башлык урынбасары | 34 725 |
| Контроль-хисап палатасы рәисе | 34 725 |
| Контроль-хисап палатасы рәисе урынбасары | 31 213 |
| Контроль - хисап палатасы аудиторы | 26 137» |

1.4 4 нче кушымтадагы таблицаны яңа редакциядә бәян итәргә:

Әлмәт муниципаль районының үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы муниципаль хезмәткәрләренә дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләр белән эшләгән өчен хезмәт хакына айлык естәмә түләү күләмнәре

| Айлык өстәмә | Айлык акчалата түләүдән, вазыйфаи окладтан, процентларда естәмәләр күләме, процентларда |
|---|---|
| «Бөтенләй яшерен» дәрәҗәсенә ия мәгълүматлар белән эшләгән өчен | 30 - 50 |
| Тикшерү чараларын үткәрүгә рехсәтне рәсмиләштергәндә “яшерен” дәрәҗәсенә ия булган белешмәләр белән эшләгән ечен,<br>тикшерү чараларын үткәрмичә | 10 – 15<br><br>5 - 10 |
| Дәүләт серен саклау буенча структур бүлекчәләрдә эшләү стажы өчен:<br>1 - 5 елга кадәр<br>5 - 10 елга кадәр<br>10 ел һәм аннан да күбрәк | <br><br>10<br>15<br>20 |

2. Әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү тиешле елга җирле бюджетта каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълумат рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайты «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карар 2023 елның 1 гыйнварыннан үз кечене керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Советының законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә (Н.В. Парфилова).

Муниципаль район Башлыгы — Т.Д. Нагуманов

МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «АЛЬМЕТЬЕВСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН» РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН • СОВЕТ АЛЬМЕТЬЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА •